

Тәҗрибәле укытучы, мәдәният сакчысы, озак еллар чын укытучы исемен йорткән Равилә Шекур кызы Тактамышева Мордовиянен Атюрьево районы Усть-Рахмановка (Аллагол) авылында 40 елдан артык татар теле һәм әдәбияты предметларын яратып укыта. Анын турында сvзебез.      Равилә Шекур кызы Тvбән Пишляй-Нижний Пишляй авылында туа һәм белем дә туган авылы топ мәктәбендә ала. Балачакта, мәктәп елларында, кон саен диярлек дуслары белән Стрельниково авылына йори; балаларны кvрше авылдагы китапханә һәм матур урта мәктәп тә җәлеп итә. Икенче яктан, яна Чадово, тоньяк яктан Пичполонга һәм Клопинка авыллары урнашкан. Бу авыл балалары рус, мордва һәм татар телләрендә бер vк торле анлашканнар, бер хезмәт коллективы «Партизанский» (СХПК) совхозында яшәvчеләрне берләштергән. Шатлык та, бәла да - барысы да урта булган бу заманда. Остәвенә, Равилә Теркулованын әтисе - Шекур Хосәен улы (мәсәлән, медаль «За отвагу»да Хусанович дип тә язылган), Боек Ватан сугышы ветераны, блокадалы Ленинградны саклаучы, озак еллар Стрельниково авыл советы рәисе булып эшләгән. Халыкнын хормәтен яулаган Шекур абый, озак еллар vз авыл халкына гына тvгел, кvрше авыллардан килеп ярдәм сораганнарга - Клопинкалыларга, Пичеполонглыларга кинәш биргән, булдыра алган кадәр ярдәм иткән.
Һәм менә Теркуловлар гаиләсендә ин кечкенәсе (ә алар гаиләдә очәv - Рашит, Рашидә, Равилә) - Равилә Шекуровна, район мәгариф бvлеге юлламасы буенча, Зубово-Поляна педагогия училищесына белем алырга бара. Бу матур яшьлек еллары, белем алу белән бергә, бvгенге колледж уку бинасын да тозергә ярдәм итv белән дә истәлекле язма героебызга. Унышлы гына укуны тәмамлап, белгечлек дипломы алгач, Атюрьево районы Усть-Рахмановка авылында укытучы биографиясен башларга туры килә ана. Р.Ш.Тактамышева, берничә ел башлангыч сыйныф укытучысы булып эшләп алгач, авыл балаларына туган тел - татар теле һәм татар әдәбияты предметларын укыта башлый. Үзе остендә педагог кvп эшли, ихластан тырыша, белемен камилләштерv максаты белән Казанга, Саранскка белем кvтәрv институтларына йори. Бар белемен, кvнекмәләрен туплап, зур теләк белән якташларынын балаларына туган телнен матурлыгына соклана белергә, яратырга ойрәтә. Ө бит туган тел - коч, ильһам чыганагы да ул. Равилә Шекуровна дәресләрендә балаларны туган телләрен кадерләргә һәм сакларга да ойрәтә. Анын тырыш хезмәте «Старший учитель» билгесе, Мордовия мәгариф министрлыгы грамоталары белән бvләкләнә. Равилә Шекур кызы Тактамышева укытучы исемен горур йортә.
- Равилә Шекуровна, туган телебезгә букадәр олы мәхәббәт орлыгын сезнен кvнелгә кем чәчте?
- Әтием, Шекур Хосәен улы, югарыда утырган лампаны аскарак тешереп, остәл тирәсенә

балаларын жыеп Габдулла Тукай, Шəриф Камалнын һəм башка татар əдəбияты классикларынын əсəрлəрен укый иде, яттан шигырьлəрен сойли торган иде. Ə əнием, Ханифə Сəлəхетдин кызы, безгə милли ризык- ларны бик тəмле пешереп ашатты, безне дə пешерергə ойрəтте. Əнием матур жырлады, Габдулла Тукай шигыренə язган жырларга кадəр койлəде; бик кvп бəетлəр белə торган иде, тик ятламаганбыз гына. Шунда, гаилəдə туган телгə мəхəббəт тəрбиялəнгəн дə инде, - диде əнгəмəдəшем.
Хəзер бу авылда мəктəп юк инде, дəреслəр дə юк, əмма кvрше татар Тенеш авылында, Равилə Шəкvровнанын оендə, бvген дə татар теленə мəхəббəт саклана - татар классикларынын китап-лары, шул исəптəн якташыбыз Абдурахман Абсалямов романнары кабат-кабат укыла. Тенештə - Татарское Тенишевода туган татар балалар язучысы Фəхрель-Ислам Агеевнын тормышы һəм ижат юлы һəрвакыт якташлары хəтерлəрендə.
«Татар теле һəм əдəбияты укытучысы Равилə Шекур кызы Тактамышева белəн беренче очрашуда ук конбатыш Мордовиядə туып-vскəн кvренекле ша-гыйрьлəр һəм прозаиклар турында бик кvп кызыклы биографик мəгълvматларны теркəп булды. Ə яна экспедиция барышында, Равилə Шекуровнанын кунакчыл оендə, Һади Такташ, Абдурахман Əпсəлəмовка һəм беренче татар балалар шагыйре Фəхрель-Ислам Агеевка багышланган видеога аерым сюжетлар да тошерелде, - ди Ренат Абянов белəн Марат Сафаров чираттагы очрашуларыннан сон. - Тəжрибəле укытучы, мəдəният сакчысы мəгълvматлары танылган якташ-ларынын ижатын кабул итvне, аларнын туган яклары белəн элемтəсен чагылдыра; əлегə кадəр билгесез булган сюжетлар да тупланган».
Сvземне дəвам иттереп, мин эше белəн горурланырлык укытучы турында язам. Анын балалары да кече Ватаннарынын горурлыгы. Равилə Шекуровна, тормыш иптəше Нуриман Сафиулла улы белəн бергəлəп, белемле, тəрбияле ике кыз – Светлана белəн Голиягə югары белем биреп, милли рухта тəрбиялилəр. Əйтеп китəргə кирəк, аларнын берничə югары белеме бар. Фотодагы Светлана Нуриман кызы – Мəскəv мəгариф депортаментында хормəтле хезмəткəр, ə Голия Нуриман кызы (ул фотода юк) – яна форматтагы Мəскəv мəктəп-балалар бакчасында тырыш эше очен Россия мəгариф министр-лыгы грамотасы белəн бvлəклəнгəн укытучы.  Светлана Сабина белəн Алинаны һəм Голия Самира исемле кыз балалар тəрбилəп vстерəлəр.
Равилə Шекур кызынын зур һəм тату гаилəсендə яшь буын да туган татар телен белə. Ул башта балаларын, аннары оныкларын классик татар əдəбияты əсəрлəре, Атюрьево ягы татарларынын гореф-гадəтлəре һəм фольклоры белəн таныштыра, ойрəтə. Əбилəре ярдəме белəн, оныклары татар йортынын эч-тəлеге, киемнəре (мисал очен, 90-еллык кəми шəле - фəйшуны да бар) моселман гореф-гадəтлəре белəн дə таныш. Жəй коннəрен авылда vткəреп, Мəскəvдəн еш кына кайткан балалар һəм оныклар Тенеш тарихын дəвам итəлəр.
Фотода сулдан унга: Самира, Светлана Нуриман кызы, Алинə, Равилə Шекур кызы, кvрше малае Ринат һəм Сабина.

**Наилə НАСЫРОВА**